ГЛАВА ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
"11" ноябрь 2022 ел.

Карар
№ 10

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Рагозино авыл җирлеге
башлыгының аерым карарларының
үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 20 маендагы 36-ЗПТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Омар авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Рагозино авыл җирлеге башлыгының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалтты дип танырга:

- Мамадыш муниципаль районы Рагозино авыл җирлеге башлыгының 2010 елның 20 августындагы «Мамадыш муниципаль районы Рагозино авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен һөнәри әзерләүгә, квалификация күтәрүгә һәм стажировкага муниципаль заказ турында» № 2 карары;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Рагозино авыл җирлеге башлыгының 2012 елның 1 августындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Рагозино авыл җирлеге органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 4 номерлы карары.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Омар авыл җирлеге
башлыгы Л.Н.Хәбибуллин